СОВЕТ БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**

**КАРАР**

**2026 елның 23 июле** Бишнә авылы **№ 43**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы Бишнә авыл җирлеге Советының 2026 елның 08 июнендәге 40 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 24 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә техник хаталарны бетерү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге Советының 2026 елның 08 июнендәге 40 номерлы карары белән расланган Бишнә авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 6 өлешендә «статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында» сүзләрен «әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 8 статьяның 1 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат эшчәнлеге рәвешләре булып:

1) җирлек Советы сессияләре эшендә катнашу;

2) җирлек Советының даими комиссияләре эшендә катнашу;

3) федераль дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына, барлык оештыру-хокукый рәвештәге оешма җитәкчеләренә, иҗтимагый берләшмәләргә мөрәҗәгать;

4) муниципаль хокукый акт проектын кертү;

5) җирлек Советы тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актлар проектларын эшләүдә катнашу;

6) җирлек Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертелә торган Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләүдә катнашу;

7) депутат гарызнамәсен кертү;

8) сайлаучылар белән очрашулар, аларның мөрәҗәгатьләре белән эшләү, үзе вәкил булган җирлек халкына үз эшчәнлеге һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү;

9) җирле референдумнарны, гавами тыңлауларны, җыелышларны, конференцияләрне һәм гражданнардан сорашып белешүләрне оештыруда һәм уздыруда катнашу;

10) территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыруда катнашу.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Бишнә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ОГРН 1021606754135 СОВЕТ БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ИНН 1620001180 КПП 162001001 ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ